**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 20 ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторына ГСМ сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, Елга урамында биек агачларны кису);
- Шәрләрәмә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);) юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу.

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина